ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» март 2022 ел № 53

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге территориясендә урнашкан "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Уразай авылында Салагыш елгасы аша күперне реконструкцияләү" линияле объектларны урнаштыру өчен территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары белән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45, 46 статьялары нигезендә, 2012 елның 7 февралендәге 13 номерлы ачык тыңлаулар нәтиҗәләре буенча беркетмәләр, бәяләмәләр, мәгълүмат нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге территориясендә урнашкан "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Уразай авылында Салагыш елгасы аша күперне реконструкцияләү" линияле объектларны урнаштыру өчен территорияне планлаштыру проектын һәм межалау проектын расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**